КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 13 июль г.Казань № 584

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эш бирүчеләрнең инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын булдыруга чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2007 ел, 5 февраль, 32 нче карары белән расланган Эш бирүчеләрнең инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын булдыруга чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эш бирүчеләрнең инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын булдыруга чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2007 ел, 5 февраль, 32 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 30 декабрь, 1141 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Эш бирүчеләрнең инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын булдыруга чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктта

в пункте 1 слова «2006 елның 24 июнендәге» заменить словами «2006 елның 19 июнендәге»;

түбәндәге эчтәлекле $3^1$ нче пункт өстәргә:

«$3^1$. Каплау өчен субсидия бирелә торган чыгымнар юнәлешләренә эш урынында хезмәтне оештыру буенча өстәмә чаралар (төп һәм ярдәмче

җайланмаларны адаптацияләүне, техник һәм оештыру ягыннан җиһазландыруны, өстәмә җиһазландыруны һәм, инвалидларның индивидуаль мөмкинлекләрен исәпкә алып, техник җайланмалар белән тәэмин итүне кертеп) үткәрүгә чыгымнар кирә.»;

4 нче пунктның беренче абзацында «нәтиҗәлеге күрсәткечләре» сүзләрен «нәтиҗәләре» сүзенә алыштырырга;

4 нче пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«һәр булдырылган махсус эш урынында инвалидларның эш белән тәэмин итү дәвамлылыгы аны булдыру чыгымнарының бер өлешен каплаган көннән кимендә бер ел эчендә.»;

8 нче пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«үзгәртеп оештыру, ябу процессында булмаган, аларга карата банкротлык процедурасы билгеләнмәгән, аларның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмаган (юридик затлар), эшчәнлеген индивидуаль эшмәкәр буларак туктатмаган (индивидуаль эшмәкәрләр);»;

9 нчы пунктның сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җитәкче (индивидуаль эшмәкәр) тарафыннан имза куелган эш бирүченең үзгәртеп оештыру, бетерү процессында булмавын, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәвен, аның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмавын (юридик затлар), индивидуаль эшмәкәр буларак эшчәнлеген туктатмавын (индивидуаль эшмәкәр) раслый торган белешмә кәгазен;»;

15 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Шартнамәдә субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше, субсидияне күчерү тәртибе, субсидия бирү нәтиҗәләренең мәгънәләре, өстәмә хисаплылык бирү вакытлары һәм формасы (кирәк булганда), эш бирүче тарафыннан субсидияне кире кайтару тәртибе, вакытлары, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан субсидия алучының субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерү, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге, Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан эш бирүченең субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвенә тикшерүләр үткәрүне гамәлгә ашыру, субидия алучының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге, Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан субидия алучының субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвенә тикшерүләр үткәрүне гамәлгә ашыруга ризалыгы, эш бирүченең бу Тәртип шартларын һәм субсидия бирү турында төзелә торган шартнамәне үтәве турында нигезләмәләр, шартнамәнең шартларын бозган өчен җаваплылык, шулай ук субидия алучының һәм халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең бу Тәртиптә каралган башка мөһим шартлары һәм бурычлары карала.

Кирәк булганда, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма буенча субсидия бирү турындагы шартнамәгә өстәмә килешү, шул исәптән субсидия бирү турындагы шартнамәне өзү турында өстәмә килешү төзелә.»;

19 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19. Субсидия алучы субсидия күчерелгән көннән бер ел эчендә ай саен, хисап аеннан соң килә торган айның 10ысыннан да соңга калмыйча, халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә бу Тәртипкә теркәлгән 3 нче кушымтада бирелгән форма буенча субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап тапшыра.»;

түбәндәге эчтәлекле $19^1$, $19^2$ нче пунктлар өстәргә:

«$19^1$. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре ай саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 15еннән дә соңга калмыйча, Министрлыкка аның тарафыннан расланган формалар буенча чыгымнарны каплау чыганаклары булып субсидия торган Татарстан Республикасы бюджетының башкарылган чыгымнары турында һәм субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап тапшыра.

$19^2$. Министрлыкка тапшырыла торган хисапларның дөреслеге өчен җаваплылык халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренә йөкләнә.»;

20 нче пунктта:

өченче абзацта «нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә» сүзләрен «нәтиҗәләренә» сүзенә алыштырырга;

дүртенче абзацта «нәтиҗәлелеге күрсәткеченә» сүзләрен – «нәтиҗәсенә» сүзенә, «3 пунктындагы» сүзләрен «4 нче пунктындагы» сүзләренә алыштырырга;

бишенче абзацта «нәтиҗәлелеге күрсәткеченә» сүзләрен – «нәтиҗәсенә» сүзенә, «3 пунктындагы» сүзләрен «4 нче пунктындагы» сүзләренә алыштырырга;

бу Тәртипкә 3 нче кушымта (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Эш бирүчеләрнең инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын булдыруга чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенә
3 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 13 июль, 584 нче
карары редакциясендә)

Форма

Эш бирүчеләрнең инвалидларны эшкә урнаштыру өчен
махсус эш урыннарын булдыруга чыгымнарының бер өлешен каплауга
субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында
хисап

| Т/с | Нәтиҗәнең исеме | Гомумроссия үлчәү берәмлекләре классификаторы буенча үлчәү берәмлеге | | Нәтиҗәнең план буенча мәгънәсе | Хисап көне хәленә карата нәтиҗәнең ирешелгән мәгънәсе | Нәтиҗәнең план буенча мәгънәсен үтәү проценты | Тай-пылу сәбәбе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | исеме | коды | | | | |
| 1. | Билгеләнгән квота чик-ләрендә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен булдырылган махсус эш урыннары саны | эш урыны | 904 | | | | |
| 2. | Һәр булдырылган махсус эш урынында инвалидларны эш белән тәэмин итү дәвамлылыгы | ай | 362 | 12 ай | | | |

Эш бирүченең исеме ____________________

____________ ____________ ____________________
(вазыйфасы) (имзасы) (имзаны таркатып язу)

М.У.*

Баш бухгалтер ____________ ____________________
(имзасы) (имзаны таркатып язу)

20__ ел, «___» ___________

____________

* Мөһер булганда.

____________